Манзарас авыл җирлеге башлыгы Татарстан Республикасы

Кукмара муниципаль районы

**КАРАР**

2023 елның 09 ноябре №106

Кукмара муниципаль районының
Манзарас авыл җирлеге
муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына, муниципаль берәмлектә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган Манзарас авыл җирлеге карар итәм:

1. «Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Кукмара муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. «Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслауту рында» карар проектын әзерләү комиссиясе тарафыннан 2023 елның 19 ноябреннән 6 декабренә кадәр экспозиция һәм Җыен үткәрү юлы белән ачык тыңлау үткәрергә.

3. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү 6 декабрьгә 15.00 сәгатьтә Манзарас авылы СДК бинасында Манзарас авылы, Яшьләр урамы, 18 нче А йорт адресы буенча билгеләнергә тиеш.

4. «Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслауту рында»» карар проекты экспозициясен һәм аңа мәгълүмат материалларын 2023 елның 19 ноябреннән 6 декабренә кадәр Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Манзарас авылы, 1 нче Май урамы, 57 нче А адресы буенча Манзарас авыл башкарма комитеты бинасындаүткәрергә;

5. Экспозициягә килүчеләргә консультацияне экспозиция урнаштырылган урын буенча түбәндәге график буенча үткәрергә: сишәмбе һәм пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда.

6. Билгеләү:

- «Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карар проекты Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырыла: http://kukmor.tatarstan.ru// 2023 елның 10 ноябреннән дә соңга калмыйча;

- карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне ачык тыңлауларда катнашучылар 2023 елның 6 декабренә кадәр ««Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карар проектын әзерләү комиссиясенә түбәндәге адрес буенча язма рәвештә кертә алалар: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Манзарас авылы, 1 нче Май урамы, 57 нче А, шулай ук язма һәм халык тыңлауларында катнашучылар җыелышы барышында телдән.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы
урынбасары В.М.Ахатов

Кушымта
проект

# КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кукмара муниципаль районының
Манзарас авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Кукмара муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, ачык тыңлаулар протоколын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карар чыгарды::

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге муниципальберәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен кушымталар нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Советының шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы С.Д.Димитриев